# ПЕЧӘН ӨСТЕ

Печән өсте, печән өсте,
Зур вакыйга авылда.
Карты-яше абый, бабай,
Бөтен халык болында.

*Кушымта:*
Мәтрүшкәле, җир җиләкле,
Эх, ул үлән исләре.
Башкайларың әйләнерлек,
Эх, ул шатлык хисләре.

Бабайларның оста итеп,
Чалгыны кыйнаулары.
Шундый да үткен иттереп,
Чалгыны кайраулары.

Инде кипкәч, өйгә ташып,
Печәнне өюләре.
Шатлык булыплар тоела,
Уф, ардым, диюләре.